**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Азнакаевского муниципаль районы**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«11» гыйнвар 2022 ел** **№ 4**

2022 елга Азнакай муниципаль районы «Яшьләр үзәге» МБУ күрсәтә торган өстәмә түләүле хезмәтләргә тарифлар турында

Азнакай район Советының 2012 елның 28 маендагы 158-21 номерлы карары белән расланган, Азнакай муниципаль районы муниципаль предприятиеләре һәм учреждениеләре товарларына, эшләренә һәм хезмәт күрсәтүләренә бәяләр, тарифлар билгеләү тәртибе белән, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының 2021 елның 13 декабрендәге 7 номерлы муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләре хезмәтләренә тарифларны (бәяләрне) карау комиссиясе утырышы беркетмәсе нигезендә, карар итә:

1. 1 нче кушымта нигезендә, 2022 елга Азнакай муниципаль районының «Яшьләр үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе күрсәтә торган өстәмә түләүле хезмәтләргә тарифларны расларга.
2. «Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм туризм идарәсе» МКУ башлыгына (Гарипов Ф.А.) Азнакай муниципаль районының яшьләр эшләре буенча ведомство буйсынуындагы муниципаль бюджет учреждениеләрендә өстәмә түләүле хезмәтләргә тарифлар куллануны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча бастырырга:http//pravo.tatarstan. һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга:http//aznakayevo.tatar.ru.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад һәм финанслар буенча урынбасары О.Н. Газизовага йөкләргә.

Җитәкче А. Х. Шәмсетдинов

Азнакай муниципаль районы
башкарма комитеты
карарына 1 нче кушымта
«____» _______2022 № _____

2022 елга Азнакай муниципаль районының «Яшьләр үзәге» МБУ күрсәтә торган өстәмә түләүле хезмәтләргә тарифлар

| № | **Түләүле хезмәтләрнең исеме** | **Тариф (бәя) сумнарда** |
|---|---|---|
| 1 | 1 сәгатькә костюмнар прокаты | 200 |
| 2 | Балалар өчен дискотекаларга билетлар: (18 яшькә кадәр) | 100 |
| 3 | Өлкәннәр өчен дискотекаларга билетлар (18 яшьтән) | 200 |
| 4 | Бәйрәм кичәләре, корпоратив чаралар, уен программалары, балалар иртәләре (2 сәгать) | 11 000 |
| 5 | Ял итү һәм тамаша чаралары үткәрү (1 сәгать) *(тематик кичәләр, квестлар, интеллектуаль уеннар)* | 2800 |
| 6 | Өстәл уеннары белән ял оештыру<br>(3 сәгать) 1 кеше («Монополия», «Башня», «Мафия», «Шашка», «Шахмат» һ. б.) | 100 |
| 7 | Белгечләр хезмәтләре (режиссер, алып баручы, һәм башкалар) 2 сәгать | 1000 |
| 8 | Концертлар, театральләштерелгән тамашалар, спектакльләр, шоу-программалар һәм яшьләр үзәге көче белән үткәрелә торган башка мәдәни чаралар.<br>1 билет<br>- балалар<br>- олылар | <br><br><br><br>100<br>200 |
| 9 | Презентацияләр әзерләү<br>текстлы ( 1 слайд)<br>- таблицалар һәм графиклар төзү (1 слайд)<br>- видеопрезентация ясау (3 мин.) | <br>30<br>50<br>800 |
| 10 | Ксерокопия (1 бит) А4 | 5 |
| 11 | принтерда текстларны бастырып чыгару А4 | 5 |
| 12 | Төсле принтерда текстлар бастыру А4 | 20 |
| 13 | Бәйрәмнәр, визиткалар, конкурс программалары, котлаулар, гаилә тантаналары сценарийларын эшләү | 1200 |
| 14 | Яңа ел, өйдә туган көн, балалар бакчасында, мәктәптә туган көн белән котлау (1 сәгать) | 800 |
| 15 | Экран белән проекторны арендалау *(1 тәүлеккә)* | 500 |
| 16 | Микшер пульты прокаты *(1 тәүлеккә)* | 500 |
| 17 | Монитор прокаты (муз.аппаратура *(1 тәүлеккә)* | 600 |
| 18 | "МЦ" МБУ биналарын арендалау (шул исәптән эксплуатация чыгымы) 1 м өчен$^{2}$ 1 сәгать эчендә. | 3,40 |